**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Чемодурово авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Чемодурово авылы № 88 «29» март 2018 ел

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге Советының 2012 елның 21 апрелендәге 42 номерлы карары белән расланган Чемодурово авыл җирлегендә гавами тыңлаулар оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә үзгәреш кертү хакында (29.01.2015 №124, 10.09.2015 №140, 04.03.2016 № 28 карарлар редакциясендә)

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 30 октябрендәге 299-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 декабрендәге 455-ФЗ номерлы Федераль законнарны үтәү йөзеннән

Чемодурово авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чемодурово авыл җирлеге Советының 2012 елның 21 апрелендәге 42 номерлы карары белән расланган Чемодурово авыл җирлегендә гавами тыңлаулар оештыру һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмәгә (29.01.2015 №124, 10.09.2015 №140, 04.03.2016 № 28 карарлар редакциясендә)1.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итеп, түбәндәге үзгәрешне кертергә:

«1.4.Гавами тыңлауларга мәҗбүри тәртиптә чыгарыла:

1) Гамәлдәге Уставны шушы норматив хокукый актларга туры китерү максатларында Уставка Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, конституция (Устав) яисә Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләрен төгәл кабатлау рәвешендә үзгәрешләр кертелгән очраклардан тыш, җирлек уставы проекты, шулай ук гамәлдәге Уставка үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында муниципаль хокукый акт проекты;

2) җирлек бюджеты проекты һәм аның үтәлеше турында хисап;

3) җирлекне социаль-икътисадый үстерү стратегиясе проекты;

4) җирлекне үзгәртеп кору турындагы мәсьәләләр, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясы нигезендә җирлекне үзгәртеп кору өчен җирлек халкының тавыш бирү юлы белән йә гражданнар җыеннарында белдерелгән ризалыгын алу таләп ителгән очраклардан тыш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чемодурово авыл җирлеге Советының законлылык, хокук тәртибе, депутат этикасы һәм җирле үзидарә мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Башлык Н.Б.Котельникова